**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Яңа Усы авыл җирлегенә керүче Бикмәч авылы**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**№ 2** **05.12.2019 ел**

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль
районының Яңа Усы авыл җирлеге составына керүче
Бикмәч торак пунктына 2020 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Яңа Усы авыл җирлеге Бикмәч торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Бикмәч торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә. Көндезге формада укучы студентларга, 1 һәм 2 төркем инвалидларга, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга һәм локаль конфликтлардагы хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Бикмәч авылы янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүгә;
- Бикмәч авылы мәдәният оешмалары хезмәтләре белән ял вакытын оештыру һәм халыкны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга;
- Бикмәч авылы җирлегендә рәсми мәдәни-массакүләм чаралар үткәрүне оештыруга;
- Бикмәч авылы җирлеген төзекләндерүне оештыруга;
- Бикмәч авылында ритуаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру һәм күмү урыннарын карап тотуга;
- Бикмәч авылы җирлегенең торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлегенә;
- Бикмәч авылы халкының күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыруга».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда, Мөслим муниципаль районы рәсми сайтының http/ muslumovo.tatarstan.ru веб-адресына һәм Мөслим муниципаль районы, Яңа Усы авылы, Совет урамы, 30 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Яңа Усы авыл җирлеге башлыгы** **Г.С. Романова**